**Класс:** 4
**Укытучы:** Касыймова Зөһрә Илсур кызы
**Программа:** Перспектива
**Тема:** Байкал күле
**Максаты**: Бөтендөнья табигать мирасы объектларының берсе - Байкал күленең үзенчәлекләрен ачыкларга, Россия картасыннан күлнең урынын күрсәтергә, контурлы карта белән эшләргә өйрәтү, экологик проблемаларны ачыклау

**Дәрес барашы:**

**-Хәерле көн, укучылар! Сезнең белән кабаттан күрешүемә мин бик шатмын. Дәресебезне башлыйбыз.**

***Слайд 2*** **Әлеге язмадан артык сүзне тап:** Идел, Зөя, Байкал.

***Слайд 3*** **Дөрес җавап ул- Байкал . Ә ни өчен сез Байкалны сайладыгыз? Чөнки ул күл, ә Зөя һәм Идел- елгалар.**

***Слайд*** **4 Узган дәрестә "Күлләр- Җир күрке" темасын өйрәнгәндә, без Байкал күлен дә карап үттек. Аның турында сез нәрсәләр беләсез? 3-4 сүз белән Байкал турында белгәннәрегезне язып куегыз.** (Укучылар яза: Байкал-күл, ул тирән, табигате матур, суы чиста, төче һ.б.(карточка бн ))

-Дәрес ахырында, сезнең дәрескә кадәр нәрсәләр белүегезне һәм дәрестә нәрсәләр үзләштерүегезне чагыштырып карарбыз.

***Слайд* 5 Ә хәзер, әйдәгез, шушы җилкәнле корабка утырып, Байкал күле буйлап сәяхәткә кузгалыйк.**

**Иң элек җыр тыңлап китик.** (**Видео + музыка** только 1 куплет)

Байкал күлләренә бардым,
Су буйларын буйладым.
Байкал күле «Уф-уф…» дигәч,
Кайгыдан дип уйладым.

Байкал күлләренә бардым,
Каршы ярын күрмәдем.
Уф — уфларың ишетсәм дә,
Эч сереңне белмәдем.

Байкал күлләренә бардым,
Кабат баралмам инде.
Салкын сулар алып эчтем —
Кабат яналмам инде.

***Слайд* 6**
Син исән-сау икән - без сәламәт,
Син авырсаң-без дә авыру.
Мәңге яшь кал, Байкал, бул гүзәл,
Энҗесе син илебезнең - диңгез-күл.

**-Ник шагыйрь Байкалны энҗе белән чагыштыра? Әллә картада бу күл энҗе формасындамы? Әллә башка сәбәпләре бармы? Дәрестә шуны ачыкларга кирәк.**

***Слайд* 7 Ә Байкал күле бездән ерак микән, ничек уйлыйсыз?**

-Язучы М.Мәһдиев "Ачы тәҗрибә" китабында менә болай дип яза: "...Без бит Байкалны үзебезнең күрше авыл күле сыман гына сизеп - тоеп үстек.
Байкал күле балыклы -

Бездә кызлар данлыклы, -   дип җырлыйлар иде өлкәннәр мәҗлестә. Ә аңа баксаң,Казаннан чыгып алты - җиде көн поезд белән барасы, чабасы икән”.   7көн ул- бер атна.

**Укучылар, әйдәгез әле Байкал күлен картадан эзләп табыйк.**  ***Слайд* 8**
***Слайд* 9**    **-Ә хәзер зәңгәр карандаш белән контурлы картадан Байкал күлен буяп күрсәтик** (раздаточный материал ).

**-“Байкал” сүзе төрки телләрдән тәрҗемә иткәндә, бай күл дигәнне аңлата икән. Нәрсәгә бай соң ул Байкал күле?** Байкал күленең табигате һәм хайваннар дөньясы белән сез әлеге сылтама аша кереп, видеоролик аша таныша аласыз. (Видеоролик карау ”Байкалның табигате”. https://www.youtube.com/watch?v=D0H2L8BxvXU

https://www.youtube.com/watch?v=zFAjAho87DE )- **экранда чыга**

***Слайд* 10** **–Укучылар, ә сез Байкал күленә ничә яшь дип уйлыйсыз? Әйдәгез шушы гамәлне эшләп карыйк:** 55 000*1000.

***Слайд* 11**   **Ничә булды?  Димәк, әлеге күлнең яше... 55 000 000.**

**Укучылар, сезнең Байкал күле турында иң кызыклы  фактларны беләсегез киләме? Алайса тыңлагыз.**

***Слайд* 12**    Байкал күле планетабызның иң чиста күле дип санала. Күлдәге суны алдан эшкәртмичә дә эчеп була.
***Слайд* 13**    Байкал күле – дөньядагы иң тирән күл. Аның иң тирән ноктасы – 1642 м.
***Слайд* 14**    Байкалга 300дән артык елга кушыла, әмма бер АнгАра елгасы гына агып чыга.
***Слайд* 15**    Байкалда имезүчеләрнең бер төре – байкал түләннәре яши. Аларның монда ничек килеп эләккәннәре әлегә билгесез, әмма алар Төньяк Боз океаныннан Енисей һәм Ангара елгалары аша монда «күченеп килгәннәр» дигән фараз бар.
***Слайд* 16**    Байкал күленең үз бәйрәме дә бар икән әле. Элегрәк ул август аеның дүртенче якшәмбесендә бәйрәм ителсә, хәзер сентябрьның икенче якшәмбесендә билгеләп үтелә.
***Слайд* 17**    Байкалның күл булуына карамастан, анда штормнар еш күзәтелә. Кайбер вакытларда дулкыннарның биеклеге 45 метрга кадәр җитәргә мөмкин.
***Слайд* 18**    Байкал бүтән сулыкларда очрамаган фаунаның төрләренә бик бай. Мәсәлән, байкал чуртаны (исеменнән күренгәнчә) бу күлдә генә яши.

**-Укучылар, хәзер мин сөйләгәннәрдән чыгып, видеороликтагы информацияне кулланып биремнәрне чишегез.**

***Слайд* 19**   Байкалның озынлыгы ------ км. Байкал - дөньядагы иң ------ күл. Аның иң зур тирәнлеге --------- м. Байкалга ---- дән артык елга һәм инеш суларын коя. Аннан бер генә елга -------- агып чыга. Ангара башланган урында ----------- поселогы урнашкан (слайд).

**- Эшләрегезне тикшерегез. Һәр дөрес җавапка бер бал куегыз.**

***Слайд* 20**    - Байкалның озынлыгы 1642м. Байкал - дөньядагы иң тирән күл. Аның иң зур тирәнлеге - 1642м. Байкалга 300 дән артык елга һәм инеш суларын коя. Аннан бер генә елга - АнгАра агып чыга. Ангара башланган урында Листвянка поселогы урнашкан.

***Слайд* 21**    **Ә хәзер әйдәгез бераз хәрәкәтләнеп алыйк.** (Физминутка. Уен. ТЕЙК ОФ - ТАЧ ДАУН структурасы)
**- Җөмлә дөрес булса, торып басабыз, дөрес булмаса - урында утырабыз.**
- Байкал ул-тау.
- Байкал ул-күл.
- Аның суы тозлы.
- Аның суы төче.
- Байкал планетадагы иң тирән күл.
- Идел Байкалга коя.
- Идел Каспий диңгезенә коя.

- Ангара Байкалдан агып чыга.
-  Казаннан ерак түгел.
- Байкал күле саклауга мохтаҗ.
- Минем Байкалда булганым бар.

***Слайд* 22**      **- Укучылар, без сезнең белән ”Мир” тирән су асты аппараты белән Байкал төбенә сәяхәт кылыйк әле.**

- Монда сирәк очрый торган балыклар (омуль, хариус) һәм гаҗәеп тюлень - Байкал нерпасы яши. Сирәк очрый торган үсемлекләрнең 2/3 Байкалда гына очрый.  Шуңа күрә дә уникаль Байкалны нәрсә белән чагыштыралар?  (Энҗе белән)

***Слайд* 23**      **Байкал күленең суы бик чиста, энҗе бөртекләре, чык тамчылары кебек, 30м тирәнлектә дә күл төбендәге балыкларны рәхәтләнеп күреп була.**

Тәҗрибә ясау.

**- Чишмә суы белән тәҗрибә ясап карыйк, суга болганчык су салсак нәрсә була?**

**- Су болгана, пычрана, төбендәге ташлар, балыклар күренми, тереклек үлә.**

***Слайд* 24**      **- Байкалга нинди куркыныч яный, аның экологиясенә нәрсәләр зыян сала дип уйлыйсыз?** Фикерләрегезне альбом битенә рәсем яки язма форматта беркетегез. (Промышленность предприятиеләре, целлюлоза-кәгазь комбинаты, браконьерлар, туристлар зыян китерә).

***Слайд* 25 Тест биремнәре.**
**1) Байкал-ул**
м) күл    н) елга    о) диңгез
**2) Аның тирәнлеге**
м) 1639м  н) 1575м   о) 1642м
**3) Нерпа-ул**
й) балык  к) кош   л) имезүче хайван
**4) Кайсы балык, уылдык (икра) чәчмичә, тере маймычлар (кечкенә балыклар) тудыра?**
н) омуль    о) голомянка    п) осётр
**5) Байкалга ничә елга, инеш үзенең суын коя?**
д) 300   е) 400   ж) 380
**6) Байкалдан кайсы елга агып чыга?**
г) Селенга   д) Идел   е) Ангара
**7) Байкал белән танышу кайсы җирдән башлана? Шунда ук музей урнашкан.**
ш) Иркутск шәһәре   ц) Листвянка поселогы   ч) Казан
**- Балалар, сезнең җаваплардан нинди сүз килеп чыкты?**  Молодец! Афәрин!
***Слайд* 26-27**
**- Дәрестә нәрсәләр белдегез? Дәрес башында язган мәгълүматларны тулыландырыгыз.**
Бөтендөнья табигать мирасы объектларының берсе – Байкал күле -----------------------( Бөтендөнья табигать мирасы объектларының берсе - Байкал күле сак мөнәсәбәткә һәм саклауга мохтаҗ.)
- Планетада башка мондый күл юк, шуңа да аны ------------------------ чагыштыралар.
( Планетада башка мондый күл юк, шуңа да аны энҗе белән чагыштыралар.)